КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 20 март г.Казань № 294

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгы мәсьәләләре» 2011 ел, 6 июнь, 460 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 26 март, 189 нчы; 2016 ел, 16 июнь, 407 нче; 2016 ел, 19 август, 572 нче; 2016 ел, 27 октябрь, 789 нчы; 2018 ел, 31 июль, 621 нче; 2018 ел, 15 декабрь, 1142 нче; 2019 ел, 18 март, 188 нче; 2020 ел, 2 март, 158 нче; 2020 ел, 13 май, 382 нче; 2020 ел, 7 август, 665 нче; 2021 ел, 2 март, 114 нче; 2021 ел, 28 июнь, 503 нче; 2021 ел, 9 сентябрь, 852 нче; 2021 ел, 6 декабрь, 1169 нчы; 2021 ел, 7 декабрь, 1179 нчы, 2022 ел, 30 сентябрь, 1053 нче, 2022 ел, 21 декабрь, 1388 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.4 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

4.1.15 пунктчада «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

4.1.16 пунктчада «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

4.1.17 пунктчада «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә инвестиция проектларын тормышка ашыруда «бер тәрәзә» принцибы буенча ярдәм итү буенча инвестиция эшчәнлеге субъектларының үзара хезмәттәшлеге регламентын раслау турында» 2019 ел, 20 февраль, 118 нче карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 27 март, 174 нче, 2022 ел, 6 апрель, 320 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә инвестиция

проектларын тормышка ашыруда «бер тәрәзә» принцибы буенча ярдәм итү буенча инвестиция эшчәнлеге субъектларының үзара хезмәттәшлеге регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.3 пунктта:

сигезенче абзацта «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

тугызынчы абзацта «Татарстан Республикасы Президентының» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенең» сүзләренә алмаштырырга;

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Муниципаль-шәхси партнерлык проектларын тормышка ашырганда Татарстан Республикасының инвестицион үсеш агентлыгы һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре җирле үзидарә органнарының үзара хезмәттәшлек итү регламентын раслау турында» 2019 ел, 22 октябрь, 949 нчы карары белән расланган Муниципаль-шәхси партнерлык проектларын тормышка ашырганда Татарстан Республикасының инвестицион үсеш агентлыгы һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре җирле үзидарә органнарының үзара хезмәттәшлек итү регламентына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

5.8 пунктның дүртенче абзацында «Татарстан Республикасы Президентының» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенең» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры — А.В.Песошин